РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 16

2021 елның 19 феврале

**Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс турында Нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрү процедурасын тәртипкә салу максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Уставының 11 статьясы, вакантлы идарә вазыйфаларын һәм Түбән Кама муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә керә торган вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру буенча үзара хезмәттәшлекне оештыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс турында» Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертү Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы тарафыннан расланган тәртиптә сайлап алу нәтиҗәләре буенча башкарылырга мөмкин дип билгеләргә
3. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 28 мартындагы 11 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында» карары һәм 2006 елның 13 октябрендәге 50 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турында Нигезләмәне раслау хакында» карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2021 елның 19 февралендәге
16 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс турында Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) белән муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә (алга таба - вакантлы вазыйфа) конкурас үткәрү тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

Әлеге Нигезләмә түбәндәге очракларда кулланыла:

- муниципаль берәмлек Уставы белән билгеләнә торган вәкаләтләр срогына контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү,

- вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү турында җирле үзидарә органнары җитәкчеләре тарафыннан карар кабул итү,

- җирле үзидарә органнары җитәкчеләре тарафыннан вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрү турында карар кабул итү.

2. Вакантлы вазыйфаны биләүгә һәм вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс гражданнарның, аларның сәләтләренә һәм һөнәри әзерлекләренә туры китереп, муниципаль хезмәткә керүгә тигез конституцион хокукын, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең конкурс нигезендә вазыйфаи үсеш хокукын тәэмин итә.

3. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча яисә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы (муниципаль хезмәткәр биләмәгән) булганда, җирле үзидарә органы исеменнән, яллаучы вәкаләтләрен башкаручы зат исеменнән игълан ителергә мөмкин.

Вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча, шулай ук Түбән Кама муниципаль районы составына керүче җирлекләрдән, яисә җирле үзидарә органы исеменнән яллаучы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы заттан, муниципаль хезмәт вазыйфаларына һәм башка идарә вазыйфаларына кадрлар резервын булдыру кирәклеге булганда игълан ителергә мөмкин.

4. Конкурста катнашуга әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында каралган срокта биргән һәм муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - гражданнар), шулай ук муниципаль хезмәткәрләр кертелә.

5. Граждан (муниципаль хезмәткәр) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәүгә, шулай ук «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми.

6. Конкурс үткәрү һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында хәбәрләр «Нижнекамская правда» һәм «Туган як» газеталарында бастырыла, шулай ук җирле үзидарә органы сайтында урнаштырыла ала.

7. Конкурс үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелә:

1) җирле үзидарә органының, вакантлы вазыйфаның тулы исеме;

2) әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъвачыга карата куелган таләпләрне үз эченә алган конкурсны үткәрү шартлары;

3) конкурсны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

4) әлеге Нигезләмәнең 9 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, аның дәвамында күрсәтелгән документлар кабул ителү срогы;

5) конкурс турында тулырак мәгълүмат чыганагы турында мәгълүматлар (телефон, факс, электрон почта, электрон адрес).

8. Конкурс үткәрү турында хәбәр конкурс уздырылуга 20 көннән дә соңга калмыйча басыла.

9. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә түбәндәге документларны тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган фотография белән анкета;

в) паспорт яисә аны алмаштыручы документ күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белем, квалификация һәм эш стажын раслаучы документлар:

- хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);

- хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган белем һәм квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданин теләге буенча, өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирүне раслаучы документлар күчермәләре, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документлар;

д) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яки аны узуга комачаулаучы авыру булмавы турында документ;

е) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» ТР Законында, башка норматив хокукый актларда каралган башка документлар.

Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиле исеменә гариза бирә.

Башка җирле үзидарә органында үткәрелә торган муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр бу җирле үзидарә органына яллаучы вәкиле исеменә гариза һәм үзе тутырган, имзалаган һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән органның кадрлар хезмәте раслаган, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча фотография белән анкета тапшыра.

Вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы (муниципаль хезмәткәр) конкурс комиссиясенә гариза тапшыра, аңа түбәндәге документлар беркетелергә тиеш:

а) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган фотография белән анкета;

б) паспорт яки аны алмаштыручы документ күчермәсе;

в) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясы);

г) хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган һөнәри белем турында, шулай ук граждан теләге буенча, өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документлар күчермәләре.

10. Гариза тапшыручы затка, исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, документлар алу турында расписка бирелә.

11. Конкурста катнашуга кертүдән баш тарткан очракта, граждан әлеге карарга гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Конкурста катнашучы теләсә кайсы вакытта үз гаризасын кире алырга хокуклы.

12. Тапшырылган документларны кабул итү һәм тикшерү конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан башкарыла.

13. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясенә конкурс үткәрү турында хәбәр басылып чыккан көннән 20 көн эчендә тапшырыла.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Документлар граждан (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан шәхсән, почта аша яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә бирелә;

14. Конкурс гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң 10 көн эчендә үткәрелә.

15. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының хокукый акты белән конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе оештырыла. Конкурс комиссиясенең персональ составы, аның эшләү вакыты һәм тәртибе җирле үзидарә органының хокукый акты белән билгеләнә.

16. Конкурс комиссиясе составына җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм (яки) аның вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләре (шул исәптән муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәләреннән, юридик (хокукый) бүлекчәләрдән, конкурс үткәрелә торган бүлекчәләрдән), бәйсез экспертлар (фәнни оешмаларның, урта, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләренең, иҗтимагый оешмаларның вәкиле (вәкилләре) керә.

Бәйсез экспертлар килешү буенча конкурс комиссиясе составына кертелә. Бәйсез экспертлар булып торучы комиссия әгъзалары саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

17. Конкурс комиссиясе рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

18. Конкурс конкурста катнашырга теләк белдергән кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфаның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

19. Тәкъдим ителгән документлар нигезендә конкурс комиссиясе кандидатларны конкурста катнашуга кертү турында карар кабул итә.

20. Конкурс үткәрү барышында, конкурс комиссиясе кандидатларны белем алу, граждан яисә башка дәүләт яисә муниципаль хезмәт үтү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы алар тапшырган документлар нигезендә, шулай ук федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү ысулларын кулланып, кандидатларның үз программаларын тәкъдим итүләрен, шәхси әңгәмәне дә кертеп, конкурс процедуралары нигезендә бәяли.

Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә, конкурс комиссиясе вакантлы вазыйфага карата тиешле квалификация таләпләрен, вазыйфа инструкциясе таләпләрен, шулай ук муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән башка нигезләмәләрне исәпкә алып эш итә.

21. Конкурс комиссиясе утырышы кимендә ике кандидат булганда уздырыла.

Кандидатлар буенча фикер алышу һәм конкурс нигезендә сайлап алу конкурс комиссиясе утырышларында гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми. Конкурс комиссиясе карарлары утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

22. Конкурс комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә.

23. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзаланган карар белән рәсмиләштерелә.

24. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы җитәкчесенең вакантлы вазыйфага конкурста җиңүчене билгеләү турында хокукый акты чыгарыла һәм конкурста җиңүче белән хезмәт шартнамәсе төзелә.

Конкурс комиссиясе шулай ук муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатларына югары бәя бирелгән кандидатны  җирле үзидарә органының кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерына ия булган карар кабул итәргә хокуклы.

Вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча җиңүчене кадрлар резервына кертү турында Түбән Кама муниципаль районы Башлыгының хокукый акты чыгарыла. Кадрлар резервына кертелгән гражданнар теркемнәре исемлегенә конкурс нигезендә сайлап алу тәмамланганнан соң өч көн эчендә тиешле язылу кертелә.

25. Вазыйфаның квалификация таләпләренә туры килгән кандидатлар булмаса яки бер генә кандидат булса, конкурс тормышка ашмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка, кандидатларның таләп ителә торган саны булмау сәбәпле, конкурс үткәрелмәгән дип язмача хәбәр ителә.

Конкурс комиссиясе тәкъдиме буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итә.

Конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатларның берсе дә вакантлы вазыйфага билгеләү өчен кирәкле тавышларны җыймаса, җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кабат конкурс үткәрү турында карар кабул ителә.

26. Конкурс комиссиясе конкурста катнашкан кандидатларга конкурс тәмамланганнан соң бер ай эчендә язма рәвештә конкурс нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

27. Конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва итүчеләрнең һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары аларга конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Әлеге вакыт чыкканчы, документлар җирле үзидарә органнары архивында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тәкъдим ителгән документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

28. Конкурста катнашу (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

29. Кандидат гамәлдәге законнар нигезендә конкурс комиссиясе карарына шикаять бирергә хокуклы.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Т.Р.Гәрәев